БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 12 2024 ел № 321

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Балтач район прокуратурасының 2024 елның 14 ноябрендәге 02-08-2024/Прдп436-24-20920011 номерлы протестын карап һәм «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021елның 04 июнендәге 183 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү буенча эш Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 1.1 пунктында «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләреннән» сүзләреннән соң», шулай ук электрон документ рәвешендә, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» (алга таба - Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, «сүзләрен өстәргә.»;

2) 1 бүлекнең 1.2 пунктының 3 абзацында «язма мөрәҗәгатькә» сүзләрен «язма рәвештә мөрәҗәгатькә» сүзләренә алмаштырырга,

3) 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы 4 абзацында «электрон почта адресы» сүзләрен «шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын (уникаль идентификатор) куллана» сүзләренә алмаштырырга, «кайсына» сүзен «кайсыларына» сүзенә алмаштырырга;

4) 1 бүлекнең 1.3 пунктындагы 2 абзацында «Президентка» сүзен «Башлыкка (Рәискә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов